**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

21.12.2020 № 374

**Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча ведомствоара эш төркеме составына үзгәрешләр кертү турында**

Аерым затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә:

«Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча ведомствоара эш төркеме турында» 2013 елның 29 мартындагы 161 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 31 гыйнварындагы 103 номерлы, 2014 елның 31 октябрендәге 632 номерлы һәм 2015 елның 14 ноябрендәге 671 номерлы, 2017 елның 17 апрелендәге 235 номерлы, 2017 елның 21 августындагы 511 номерлы, 2018 елның 13 апрелендәге 154 номерлы һәм 2020 елның 17 апрелендәге 146 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча ведомствоара эш төркеме (алга таба – эш төркеме) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эш төркеме составыннан Н.М. Владимировны, Р.Г. Гаффаровны, М.Ш. Долговны, Р.З. Закировны чыгарырга;

эш төркеме составына кертергә:

Заика Алексей Михайловичны – Татарстан Республикасы Прокуроры урынбасарын (килешү буенча);

Кадыйров Тимур Рәфкать улын – Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясе советы рәисен (килешү буенча);

Скирда Максим Владимировичны – Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Шакиров Данис Фәнис улын – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Яковлев Константин Геннадиевичны – Татарстан халыклары ассамблеясе советы Башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан халыклары ассамблеясе советы рәисе урынбасарын (килешү буенча);

эш төркеме әгъзаларының вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.Р. Дирзизовның – «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе башлыгы»;

К.И. Сәмигуллинның – «Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие (килешү буенча)»;

И.Г. Һадиуллинның – «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры».

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ